| | |
|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» 11 2022 ел № 334

«Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2022 елның 28 октябрендәге 305 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указына туры китереп, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2022 елның 28 октябрендәге 305 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«1.3. 2022 елның 1 декабреннән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына караган мәктәпләрдә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә өстәмә белем бирү түгәрәкләрендә һәм секцияләрендә дәресләр өчен түләүдән азат итү;

1.4. 2022 елның 1 декабреннән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендәге музейларга бушлай керү;

1.5. 2022 елның 1 декабреннән бушлай спорт — «Дулкын» тренажер залы булган ябык йөзү бассейны һәм спорт заллары;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов